КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 3 июнь г.Казань № 518

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләмнәренең планлы күрсәткечләрен һәм әлеге керемнәрдән (максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш) эш хакын түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен билгеләү турында» 2021 ел, 13 декабрь, 1212 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләмнәренең планлы күрсәткечләрен һәм әлеге керемнәрдән (максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш) эш хакын түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен билгеләү турында» 2021 ел, 13 декабрь, 1212 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

«1$^1$. Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән план күрсәткечләреннән тыш түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләме, максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, алар хезмәт хакының план күләме һәм түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәрнең план күләме нисбәтен исәпкә алып билгеләнә торган күләмдә хезмәт хакы түләүгә җибәрелә дип билгеләргә, Татарстан Республикасы тиешле дәүләт бюджет учреждениесе буенча максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш.»;

2 пунктта «1 пункт» сүзләрен «1 һәм 1[1] пунктлар» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 3[1] пункт өстәргә:

«3[1]. Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениеләренә һәм муниципаль учреждениеләргә тәкъдим итәргә:

тәкъдим ителгән план күрсәткечләреннән артыграк алынган түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәрне, әлеге карарга 2 нче һәм 3 нче кушымталарда билгеләнгән максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, хезмәт хакының план күләме һәм түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәрнең план күләме нисбәтен исәпкә алып билгеләнә торган күләмдә хезмәт хакын түләүгә юнәлдерергә, Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе һәм муниципаль учреждение буенчамаксатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш;

күрсәтелгән учреждениеләр тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрдән һәм әлеге карарга 2 нче һәм 3 нче кушымталар нигезендә түләүле хезмәтләр күрсәтүдән планлы күрсәткечләрдән артык алынган керемнәдән, әлеге карарның 3 пунктының икенче һәм өченче абзацлары һәм әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә хезмәт хакын түләүгә җибәрелә торган түләүле хезмәт күрсәтүләрдән күрсәтелгән керемнәр күләменең 50 проценттан артыгын административ-идарә персоналына хезмәт хакы түләүгә җибәрергә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин